КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1099

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) алга таба таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарның гамәлдә булуын туктатып тору һәм яңарту тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хәлен һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) алга таба таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарның гамәлдә булуын туктатып тору һәм яңарту тәртибен расларга.
2. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 17 ноябрь, 1099 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) алга таба таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарның гамәлдә булуын туктатып тору һәм яңарту
тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) алга таба таралуны булдырмау максатларында кертелгән тыюлар һәм чикләүләр гамәлдә булган чорда ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарның гамәлдә булуын туктатып тору һәм яңарту механизмын җайга сала.

2. Ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарның гамәлдә булуын туктатып тору Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән гражданнар категорияләренә карата гамәлгә ашырыла.

3. Ташламалы транспорт кушымталы электрон карталарның гамәлдә булуын туктатып тору сроклары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны булдырмау максатларында мәгълүматны вакытлыча исәпкә алу кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 373 номерлы карарында Вакытлыча исәпкә алу кагыйдәләре расланган яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) таралуны булдырмау максатларында мәгълүматны исәпкә алу буенча мәгълүмат ресурсыннан, «Татарстан Республикасының электрон сәламәтлек саклавы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан мәгълүматларны юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторларының мәгълүматлар базасында автомат режимда интеграцияләүне тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторлары белән үзара эш мөнәсәбәтләре хезмәттәшлек турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аның белән «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе килешү арасында төзелгән килешү нигезендә юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторына бирелә торган мәгълүматларны көн саен һәр эш көнендә актуальләштерүне тәэмин итә.

7. Юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы мәгълүматлар базасына туктатып тору өчен нигезләр булу турында мәгълүматлар кергән вакыттан 24 сәгать

эчендә ташламалы транспорт кушымталы электрон картаның гамәлдә булуын туктатып торуны тәэмин итә.

8. Ташламалы транспорт кушымталы электрон картаның гамәлдә булуын яңарту юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторының мәгълүматлар базасына аның гамәлдә булуын туктатып тору нигезләрен бетерү турында мәгълүматлар кергән вакыттан 24 сәгать эчендә гамәлгә ашырыла.

9. Бу Тәртипне куллану турында аңлатмалар бирү Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, юл йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасы операторлары тарафыннан тиешле компетенция чикләрендә башкарыла.

___